КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 май г.Казань № 387

Татарстан Республикасының «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасының «Төзелештә тикшерүләр һәм сынаулар үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба – Учреждение) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Учреждение эшчәнлегенең төп максатлары итеп капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә хокук бозуларны ачыклау һәм кисәтү максатларында тикшерүләр, лаборатор һәм башка сынаулар уздыруны билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә:

Учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкарырга;

30 көн эчендә Учреждение уставын расларга һәм законнар нигезендә кирәкле башка оештыру чараларын үтәргә;

Учреждение уставын теркәгәннән соң 10 көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеген Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә;

ел саен учреждение уставында каралган эшчәнлекнең төп төре нигезендә Учреждение өчен дәүләт йөкләмәсен һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын расларга.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына әлеге карарның 3 пунктында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген тапшырганнан соң 30 көн эчендә Учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен оператив идарә хокукында законнарда билгеләнгән тәртиптә

Учреждениегә беркетергә, шулай ук Учреждениегә түләүсез файдалануга тапшырырга.

5. Учреждение тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

6. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе белән берлектә, Учреждение уставы раслангannan соң 60 көн эчендә Учреждение тарафыннан дәүләт эшләрен (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруга (күрсәтүгә) норматив чыгымнарны раслау турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин